РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
**ГЛАВА**
**СТАРОКАЗЕЕВСКОГО**
**сельского поселения**
***Камско-Устьинского***
**муниципального района**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
***Кама Тамагы***
**муниципаль районы**
**ИСКЕ КАЗИЛЕ**
**авыл җирлеге**
**БАШЛЫГЫ**

ул. Центральная, 7, д.Караталга, 422834
тел. (8-843-77)30-4-16, факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

Үзәк урамы, 7 , Каратал авылы, 422834,
тел. (8-843-77)30-4-16 , факс: (8-843-77)30-4-16
ОКПО 04306776 ОГРН 1031638402201
ИНН/КПП 1622001844/162201001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

**1 декабрь 2021 ел** **№ 25**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Каратал авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында" 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Кама-Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Уставы нигезендә хэм халык җыенын үткәрүгә әзерлек чорында кертелгән тәкъдимнәрне һәм өстәмәләрне исәпкә алып (Каратал ТИҮ җитәкчесе Гыймадиев М. М.) **карар бирәм:**

**1.** Иске Казиле авыл җирлеге башлыгының 2021 елның 24 ноябрендәге “Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Каратал авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча халык җыенын билгеләү турында” гы 19 номерлы карарын гамәлдән чыгарырга

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенең Каратал торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын 2021 елнын 11 нче декабренэ билгеләргә:
   1.1. Халык жыенын уткэру вакыты - 2021 елнын 11 декабрендэ 10.00 сэгатьтэн 12.00 сэгаткэ кадэр.
   1.2. Уткэру урыны-Каратал авылы, Купер урамы, мэдэният йорты бинасы янында.

2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган түбәндэге мәсьәләне расларга:

«Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлегенә кергән Каратал торак пункты территориясендә

яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән (көндезге формада белем алучы студентлардан тыш) 2022 елда 1700 сум күләмендә үзара салым кертү белән һәм җыелган акчаларны, җирле әһәмияттәге мәсьәләләр буенча түбәндә язылган эшләрне хәл итүгә куллану белән килешәсезме:

1) Каратал т. п. буенча юл-урам челтәрен төзекләндерү (вак таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү) ;
2) Каратал т. п. юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
3) Каратал т.п. территориясен чуп улэннэреннэн чистарту (чапкыч очен запас частлэр сатып алу, ягулык-майлау материаллары сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
4) Торак пункт территорияләрен төзекләндерү (урамда бизэу очен яңа ел чыршыларына бизэклэр сатып алу);
5) Иске Казиле т. п. да янгын гидрантларын тэртиптэ тоту (янгын гидрантларын, краннарны (җайланмаларны) кышка җылыту, люкларны кардан, боздан даими чистарту, язгы-җәйге янгын куркынычы чорына әзерлек һәм тикшерү, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)
6) Каратал т. п. Ял зонасы төзү буенча эшләр башкару (ызанлау чыгымнарын түләү, инвентарь сатып алу һәм урнаштыру; кое макетын булдыру, газон чәчү килешү буенча эшләр өчен түләү);
7) Каратал т. п. зираты территориясен төзекләндерү (бункер сатып алу һәм урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү);
8) суүткәргечне һәм су белән тәэмин итү коеларын ремонтлау (материаллар сатып алу, эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

« ӘЙЕ» «КАРШЫ»

4. Әлеге карарны мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә билгеләнгән тәртиптә урнаштырырга.
5. Әлеге карар ул басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы Кама
Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге
Башкарма комитеты җитәкчесе ________________И.Х.Сәгдиев